КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 7 апрель г.Казань № 954

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга амбулатор гемодиализ һәм перитонеаль диализ хезмәтләре күрсәтүне оештыруга норматив чыгымнар һәм хезмәтләр күләмнәре турында» 2016 ел, 10 ноябрь, 837 нче карары белән расланган 2017 елга хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга гемодиализ үзәкләре (бүлекләре) күрсәтә торган амбулатор гемодиализ һәм перитонеаль диализ хезмәтләре күләмнәренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга амбулатор гемодиализ һәм перитонеаль диализ хезмәтләре күрсәтүне оештыруга норматив чыгымнар һәм хезмәтләр күләмнәре турында» 2016 ел, 10 ноябрь, 837 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 13 гыйнвар, 3 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2017 елга хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга гемодиализ үзәкләре (бүлекләре) күрсәтә торган амбулатор гемодиализ һәм перитонеаль диализ хезмәтләре күләмнәренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Амбулатор гемодиализ хезмәтләре күрсәтү» бүлегенең 1 пунктында «68 796» һәм «37 596» саннарын тиешенчә «76 242» һәм «45 042» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры А.В.Песошин